№1 апрель
2021

# адымнар татар

*Зур җиңүләр кечкенә адымнардан башлана*

# Татарның Тукайлы 135 нче язы!





2 нче бит



7 нче бит



4 нче бит

# «Бал кортлары» – җиңүче!

**Светлана Скарьдова:**




«Татар-дозор» – ул команда уены. Ничек итеп тиз генә кирәкле урынны табарга? Табышмакларны тиз чишәргә? Командада төгәл бүленеш кирәк, фикерләү дөрес юнәлештә бармаса булмый. Уен 26 сораудан торды. Безгә телеграмм ботыннан сораулар килде, алар күбрәк бина яки һәйкәлләр белән бәйле иде. Җавапны тапкач, шул урынга барып, хәрефләр эзлисең. Аларны телеграммга язасың һәм тагын яңа сорау килә. Иң күңелле квест булып хәтердә калыр бу «Татар-дозор».

**Ясминә Әхмәтҗанова:**



«Татар дозор» – яңа маҗаралар һәм бердәмлек, команда белән эшләү ул. Квест шактый арытты, әмма бу ләззәтле ару иде. Без барысына да өлгердек бит! Киләсе елга да катнашырга исәп, тәҗрибә тупладык, нәрсә эшләргә кирәклеген беләбез хәзер. Җиңәр өчен төрле урыннарда ориентлаша белү дә мөһим, тарихны һәм әдәбиятны белергә кирәк».

**Камилә Юнысова:**



«Татар-дозор» минем өчен – яңа тәҗрибә. Бу квест вакытында без команда белән якынайдык һәм бер-беребезне яхшырак тоя башладык. Нәрсә турында сүз барганны аңлау авыр иде. Һәм шул урынны калган командалардан иртәрәк табарга кирәк бит – уен ахырына кадәр шул тынычлык бирмәде. Җиңәр өчен һәрбер катнашучының командада эшли белү сәләте дә мөһим».

**Алия Хәсәнова:**



«Татар дозор» – үзеңне яңа яктан сынап карау мөмкинлеге. Квест вакытында Казанга бөтенләй башка күзлектән карадым, миңа билгеле булмаган бик күп истәлекле урыннары бар икән. Җиңел булмады. Җиңәр өчен зур игътибарлылык, кыюлык, татар телен шәп белү кирәк, һәм, әлбәттә, яхшы кәеф булырга тиеш».

**Раяна Дәүләтшина:**



«Татар-дозор» – ул үзең яшәгән җирләрне яңа яктан күрү. Төрле яңа кешеләр белән танышу. Үзеңә яңа белем туплау. Авыр булмады. Житезлектә сыналдык, Казан тарихы турында яңа фактлар белдек, дуслар белән күңел ачтык. Җиңәр өчен житез, кыю, тиз аңлаучан булырга кирәк».

**Сафия Федотова:**



«Татар-дозор» – ул файдалы һәм күңелле үткәрелгән вакыт, төрле яктан белемнәрне тикшерү. Көрәш шундый иде: җавабың дөрес булса гына, алдагы сорау җибәрелә. Географик, тарихи, иҗади һәм әдәби яктан белемнәр яхшы булырга тиеш. Казанның элек мин белмәгән истәлекле урыннарында булу аеруча мавыктыргыч. Киләсе елга да барырга теләгем зур».

Рүзәл Салихов әзерләде. 8 «Е»

# Татарның Тукайлы 135 нче язы!

13 апрель көнне безнең 8 «Е» сыйныфы, җитәкчебез Рамил Ханнанов белән, Арча районына сәяхәт кылды. Безне тарихчы-галим Ленар Гобәйдуллин озатып йөрде.

Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктә урнашкан музеена барганда, язгы үзгәрешләргә сокланып, урман-болыннарны, су буйларын фотога төшердек. Гаҗәеп табигать! Арча районыннан әдәбиятыбыз күген балкыткан шәхесләр чыгуы табигый: бөек Тукай, драматург Галиәсгар Камал, халык язучылары Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов, Рафаил Төхфәтуллин һәм башкалар. Гөберчәк авылына килеп җиткәч, М.Мәһдиевнең тормышын һәм иҗатын тагын бер тапкыр искә төшердек. Язучының без укыган «Без – кырык беренче ел балалары» һәм «Кеше китә – җыры кала» повестьлары буенча экскурсовод сораулар бирде. Төркемнәргә бүленеп, кроссвордлар чиштек, логик биремнәргә җавап эзләдек.

Шуннан соң без Кырлайга – бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның балачакта яшәгән авылына юл тоттык. Музейның беренче каты дүрт залга бүленгән: кечкенә Апуштан бөек Тукайга әйләнгәнчегә кадәрге тормыш юлы биредә ачык күренә. Икенче кат – шагыйрьгә һәм аның иҗатына багышланган картиналар галереясе.

Экскурсия беткәч, без «Адымнар-Казан» мәктәбе укучылары һәм аларның әтиләре ясаган сыерчык ояларын Кырлайның Сыерчыклар аллеясына бүләк иттек, шигырьләр укыдык.

Ахырдан Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә, дөньяда бердәнбер «Әлифба музее»нда булдык. Безне, өч төркемгә бүлеп, бик күп кызыклы мәгълүмат белән таныштырдылар. «Әлифба ничәнче елда төзелгән?», «Кем аны уйлап тапкан?», «Ни өчен «Әлифба музее» нәкъ менә Арча районында урнашкан?», «Ничәнче елларда беренче татар кызлар мәктәбе ачылган?» һәм башка сорауларга җавап белә алдык.

Искиткеч кызыклы һәм эчтәлекле бу сәяхәтне төрле мәдәни һәйкәлләре, музейлары белән нурлы хатирә буларак истә калдырдык.









**Гәүһәр Гарифуллина. 8 «Е»**
**Ленар Гобәйдуллин фотолары**

# Кем булган ул Бондаренко?

***Безнең мәктәп Бондаренко урамында урнашкан. Кем булган соң ул Бондаренко? Әһә, белмисезме?! Хәзер сөйлим!***

Казанның Җиңү паркыннан башланып киткән, әй, юк ла, безнең күркәм «Адымнар» мәктәбеннән башланган урам Александр Бондаренко (1922-1997) исемен йөртә. Аның исеме очраклы гына бирелмәгән. Бондаренко 1965-1985 елларда Казан мэры булган. Бөек Ватан сугышында да катнашкан.

Александр Иванович хезмәт карьерасын тимер юл транспортында башлый. 1955 елда аны Горький тимер юлының Казан бүлекчәсенә партия оешмасы секретаре итеп сайлыйлар. Ун елдан соң ул Казан шәһәре Халык депутатлары советы башкарма комитеты рәисе була. Бу постта ул 20 ел эшли, Казаныбызга зур үзгәрешләр кертә: Таулар, Заречье, Танкодромда торак төзелеше башлана. Төп магистральләр – Ямашев, Ибраһимов, Татарстан, Фрунзе урамнары формалаша. Нәкъ менә Бондаренко Казан метрополитенын төзү инициаторы була. Казан университеты корпуслары, Галиәсгар Камал исемендәге театр, «Казан» милли-мәдәни үзәге, «Татарстан» кунакханәсе, Яшьләр үзәге, Спорт сарае һәм Үзәк стадион төзелә.

Бондаренко чорында Татарстан башкаласы миллионлы шәһәр статусын ала.



**Адилә Ахунова. 7 «Ж»**

**Бездә кунак бар**

# Көлү ничә төрле була?



***8 апрель көнне безнең белән очрашуга язучы-сатирик, юмор остасы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Кәримов килде. Ул үзенең балачагы, ничек язучы булып китүе, бүгенге әдәбият турында сөйләде. Безгә көлү төрләре – юмор, ирония, сатира, сарказм турында дәрес бирде.***

Бигрәк тә миңа Камил абыйның «Карурманда кара песи» әсәренең язылу тарихын сөйләве ошады. Язучының бер кечкенә генә вакыйганы ничек итеп зур әсәргә әйләндерүе турында ишетү кызыклы булды. Камил Кәримов китапханәбез фондына 382 китап бүләк итте.

**Әнвәр Хәйретдинов. 6 «З»**

**Әдәби кичә**

# Шагыйрьле дәрес




***Апрель ае – шигърият ае. Шуңа күрә бу айда безнең мәктәптә дә әдәби чаралар еш уза, очрашуга язучы-шагыйрьләр килә.***

20 апрель көнне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Укучылар шагыйрьнең шигырьләрен укыды, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды.

Кичәгә Равил ага Фәйзуллин үзе дә улы Газиз белән килгән иде. Ул сәхнәдән шигырьләрен укыды, безнең бик күп сорауларыбызга җавап бирде. Шигырьләрне шагыйрьнең үзе укуында ишетү бик дулкынландыргыч булды. Шул рәвешле, шагыйрьле әдәбият дәресе күңелләргә якты хатирә буларак уелып калды.

**Сәидә Сафина. 5 «Ж»**

---

**И газиз телем минем!**

# Ана һәм Кыз

***Лагерьдан кайткач, бер кыз әнисенә әйткән:***

***– Бер генә татарча шигырь дә өйрәтмәгәнсез. «Һәркем үз туган телендә шигырь сөйләсен», – диделәр. Шулхәтле хурландым.***

Шагыйребез Шәүкәт Галиевнең лирик язмаларын укыганда, әлеге юлларга күзем төште дә уйланып калдым. Күңелемнән Ана белән Кыз диалогын дәвам итеп карадым. Ул, нигәдер, русча булып чыкты. Сезгә татарчага тәрҗемә итеп язам. Туган телендә бер шигырь дә сөйләп күрсәтә алмаган кыз татарча белмидер кебек тоелды миңа. Әле әнисе беләме икән?!

А н а. Кызым, шигырь өйрәтеп була ул... Тик сиңа татар теле киләчәктә кирәк булырмы соң?

К ы з ***(бераз уйлап торгач).*** Кирәк булыр, әнием... Минем, туган телемдә, саф татарча сөйләшеп, шигырьләр, әдәби әсәрләр укыйсым килә.

А н а. Белмим шул инде, кызым... Әнә, Казанда «Адымнар» мәктәбе ачылган, дип сөйләделәр телевизордан. Укырга шунда күчәсең килмиме соң?

К ы з. Уйларга кирәк, әнием...

Дәвам итеп тормыйм. Нәтиҗәне үзегез ясарсыз... Мин бер нәрсәне ачык аңлыйм: Ана телен яраткан кеше генә Җир йөзендә зур бәхеткә лаек!

**Раяна Дәүләтшина. 8 «Е»**

# Тиенкәй

**Әкият**

***Кара урманда бер тиен кызы яшәгән. Ул бик шук һәм кызыксынучан булган. Дуслары да күп икән.***

***Беркөнне тиенкәйнең әнисе аңа гөмбә, җиләк-җимеш һәм чикләвек җыярга кушкан.***

– Кызым, кыш бик озын, ач торып булмас. Алдан әзерләник! – дигән.

Тиенкәй дусларын чакыра: ак тәпиле куян кызын, көчле аю малаен, зирәк һәм хәйләкәр төлке кызын, сөйкемле һәм батыр бүре малаен. Алар, бергәләшеп, урман буйлап сәяхәткә китәләр. Бара торгач, урман куелыгында үсеп утырган карт юкәгә юлыгалар. Аның кәүсәсендә зур гына куыш бар икән, һәм шунда шөпшәләр оялаган. Аю баласы моны күрә дә:

– Шәп булды! Хәзер бал белән сыйланабыз! – дип кычкырып җибәрә һәм юкәгә менеп китә.

Калганнар исә, аңа бераз карап торалар да, кәрзиннәренә җиләк җыя башлыйлар. Якында гына сазлык була. Куян кызы ялгыш шул сазлыкка барып чыга. Үзе дә сизмәстән, бата башлый. Дусларын ярдәмгә чакыра:

– Коткарыгыз! Коткарыгыз! Ба-та-ам!..

Җиләк җыеп йөргән җәнлек балалары барысы да ярдәмгә ашыга. Әмма да ләкин сазлык куян кызын шулкадәр каты итеп суырган, тартып чыгарырга көчләре җитми икән. Шулвакыт көчле аю малаеның юклыгы исләренә төшә. Аны чакыралар да, ул куянкайны сазлыктан тартып чыгара.



*Раяна Дәүләтшина иллюстрациясе*

Бераз хәл алгач, нәни дуслар, шатланышып, тагын урман буйлап китәләр. Баралар, баралар һәм Шүрәлегә юлыгалар. Ә Шүрәленең җәнлек балалары белән кети-кети уйныйсы, аларны алдалап адаштырасы килә икән. Шүрәленең бу мәкерле хәйләсен зирәк төлке кызы бик тиз сизеп ала һәм үзен алдый.

– Шүрәле абый, без бик арыдык. Ашыйсыбыз килә.

Ач килеш бер дә уйный алмабыз шул. Син безгә тәмле ризыклар алып килче! Без шушы аланда сине көтеп торырбыз, – ди.

Шүрәле өенә кереп китүе була, җәнлек балалары урман куелыгына кереп йөгерәләр. Шактый озак йөгерәләр алар һәм юлны югалтып адашканнарын аңлыйлар.

Батыр бүре малае бераз уйлап тора да, зирәк төлке кызы белән киңәшкәч, кайтыр юлның планын төзи.

Зур авырлыкларны җиңеп, дуслар кайтырга чыгалар. Урман аланнарында туктап, кәрзиннәрен гөмбә, җиләк-җимеш белән тутыралар, чикләвек тә җыялар.

Тиенкәйнең әнисе аларны бик шатланып каршы ала. Кызы урманда күргән маҗараларны сөйләгәч, ул болай ди:

– Күрдегезме инде, балалар: дуслык барлык авырлыкларны да җиңәргә булыша. Һәрчак шулай дус, бердәм булып яшәгез. Бердәмлектә – көч!

**Нурия Хөсәенова. 6 «Е»**

# Зур җиңүгә – адымлап...




Быелгы яз безнең укучылар өчен Шаяннар һәм тапкырлар клубы уеннары белән дә истә калачак. Казан лигасының сайлап алу этапларын уңышлы узып, 7 команда «Адымнар-Казан» күптелле комплексында көч сынашты.

### *Нәтиҗәләр:*

*I урын – «Адымнар» командасы;*
*II урын – «4 нче гимназиянең җыелма командасы» һәм*
*145 нче лицейның «ФизМатиклар» командасы;*
*III урын – 14 нче гимназиянең «Ерык авызлар» командасы.*

Казан лигасының 30 апрель көнне узачак Гала-концертында 10 команда катнашачак. Гала-концертта җиңгән команда «Әйдә, ШаяРТ!» телевизион проектының 1/2 финалына эләгә!

***«Адымнар» командасына зур уңышлар телибез!***




«Адымнар-Казан» күптелле белем бирү комплексының
«Журналистика» түгәрәгенә йөрүче укучылар газетасы
Чыгаручы мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Вёрстка һәм дизайн – Руслан Шәмсетдинов
Газетаны гамәлгә куючы: «Адымнар-Казан» күптелле белем бирү комплексы
Тираж – 999 данә

# Яхшы кәеф чыганагы

***Шушы көннәрдә «Минем мәктәп мажаралары» тапшыруының беренче серияләре чыкты.*** Казан шәһәре һәм «Адымнар» мәктәбе укучылары өчен татарча шаян тапшыру төшерү бик шәп тәҗрибә булды. Үзенең төзелеше белән ул күпләргә таныш «Ералаш» тапшыруын хәтерләтә. Шуңа күрә ул балалар өчен дә, өлкән буын вәкилләренә дә бик якын.

Беренче эш итеп, сценарий язу һәм заман укучысына типик туры килгән образлар табу максаты куелды. Шуннан соң төшерү эшләре башланды. Укучылар да, укытучылар да яратып, хуплап кабул итте бу яңалыкны.

Сценарий авторлары һәм төп актёрлар – Югары татар КВН лигасы чемпионнары, «Әкәмәт» иҗат берләшмәсе резидентлары.

Кайчакта без – укучылар – мәктәптән өйгә начар кәеф белән кайтабыз, түбән билгеләр кәефне төшерә. «Минем мәктәп мажаралары» нәкъ менә шундый мизгелләрдә кирәк тә инде. Аның туган телебездә булуы һәм үз мәктәбебез тормышын үзәккә куюы аеруча әһәмиятле. Өйдә дә мәктәп дөньясының күңелле сәхифәләрен барлау, әти-әниләргә күрсәтү кәефне күтәрә, йөзләрдә елмаю барлыкка китерә.

**Нариман Вилданов. 8 «Е»**



# Укучы мәзәкләре

***

Бер кечкенә малай уенчыклар кибетендә машина сорап ала да сатучыга уенчык акча бирә. Сатучы апа пырхылдап көлеп җибәрә.
– Нигә көләсез? – дип сорый малай. – Әллә уенчык машинагыз өчен чын акча бирер дип уйладыгызмы?!

***

Фигыль заманнарын өйрәнгәдә, укытучы:
– Әгәр, мин сукалыйм, чәчәм, тырмалыйм, урам, дисәм, бу фигыльләр кайсы заманда булыр? – дигәч, Вәли, аны-моны уйлап тормастан: «Борынгы заманда, апа!» – дип әйтеп салды.

***

Вәли мәктәптән кайта да, өй каршына басып, бөтен урамны яңгыратып:
– Әни, әни! Әни, дим! Ә-ни-и-и! – дип кычкыра икән.
Тавышны ишетеп, күршеләр, янәшә йортларда яшәүчеләр дә тәрәзәләренә каплана. Вәлинең куркынган әнисе балконга йөгереп чыга:
– Нәрсә булды, улым? Ник кычкырасың?
– Әтине чакыр әле!

***

– Әти, ә син беләсеңме: бер тюбик теш пастасы күпмегә җитә?
– Белмим шул, улым...
– Исеңдә калдыр: залны, аш бүлмәсен әйләнеп чыгарга! Һәм ярты балконга да кала әле!..

**Фәрит Вәлиев. 6 «З»**